ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 03 2024 г. № 52

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 74 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Түбән Кама шәһәренең Башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 74 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза кергән көннән соң 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта - гариза килгән көннән соң 5 эш көне эчендә.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
торак сәясәте бүлеге башлыгы Р.Ф. Хәйруллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881